# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлеге Степановка торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**18.11.2022ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ атарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 25 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: 2023 елда Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Степановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Степановка торак пунктында һәлак булган сугышчыларга обелиск территориясен төзекләндерү (койма кую, килешү буенча эш өчен түләү).

2) Степановка торак пунктында Богдановка урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 45 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 25 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“РИЗА” позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 25 кеше тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлегенең Степановка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. Сорау буенча карар кабул ителде дип таныргa: 2023 елда Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Степановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү

1) Степановка торак пунктында һәлак булган сугышчыларга обелиск территориясен төзекләндерү (койма кую, килешү буенча эш өчен түләү).

2) Степановка торак пунктында Богдановка урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) - кабул ителгән дип таныргa.

3. Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлеге башлыгы __________________ А. М. Галимов
(имза)